**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ГЛАВА ПСЕЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МЕНДЕЛЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423646 Республика Татарстан, Менделеевский район, д.Псеево
ул. Центральная, д.4

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**МЕНДЕЛЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ПЕСӘЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

423646 Татарстан Республикасы, Менделеевск районы,
Песәй авылы, Үзәк урам,4 йорт

Тел. (факс): (85549) 3-71-22 e-mail: Psv.Men@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

8 ноябрь 2024 ел № 9

Татарстан Республикасы Менделеевск
муниципаль районы Песәй авыл җирлегенең
Песәй авылында гражданнарның
үзара салым акчаларын кертү һәм
куллану мәсьәләсе буенча гражданнар
җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы «Песәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы "Песәй авыл җирлеге" башлыгы КАРАР БИРӘ:
2024 елның 22 ноябре 14.00 сәг. Менделеевск муниципаль районы Песәй авыл җирлегенең Песәй авылында Яшьләр урамы, Яшьләр тыкрыгы буенча гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын билгеләргә.

1. 2024 елның 22 ноябре 15.00 сәг. Менделеевск муниципаль районы Песәй авыл җирлегенең Песәй авылында Үзәк һәм Мичурин урамнары буенча гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын билгеләргә.
2. 2024 елның 22 ноябре 16.00 сәг. Менделеевск муниципаль районы Песәй авыл җирлегенең Песәй авылында Тукай, Чишмә, Дала урамнары һәм Дала тыкрыгы буенча гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының өченче этабын билгеләргә.
3. Җыен этапларын уздыру урыны итеп Песәй авылы, Мәктәп тыкрыгы, 3 йорт адресы буенча Песәй авыл мәдәният йортын билгеләргә. Песәй авылында яшәүчеләр исемлеген җыен этапларына бүлүне территориаль билге буенча түбәндәге тәртиптә башкарырга:

   Беренче этап: Яшьләр ур., 1-28 й., Яшьләр тыкрыгы 3-5 й
   - Икенче этап: Мичурин ур., 1-27 й., Үзәк ур., 1-19 й.
   - Өченче этап: Тукай ур., 1-37 й., Чишмә ур., 1-13 й., Дала ур., 1-16 й. Дала тыкрыгы, 1-9 й.
4. «2025 елда үзара салым акчаларын Менделеевск муниципаль районы Песәй

авыл җирлегенең Песәй авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә, I-II төркем инвалидлардан, тыл ветераннарыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, балигъ булмаган күп балалы гаиләләрдән, югары һәм урта уку йортларының көндезге бүлегендә укучы студентлардан, Россия Армиясенә сроклы хезмәткә чакырылган гражданнардан 500 сум күләмендә, махсус хәрби операциядә катнашучылардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, кертүгә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге ихтыяҗларга юнәлтергә сез ризамы" дигән сорауны расларга.

«1) Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Мичурин, Чишмә, Тукай, Дала урамнары, Дала тыкрыгы урамнары буйлап җирлек эчендәге юлларны ремонтлау (вак таш сатып алу, ташу, шартнамә буенча эшләр өчен түләү), Песәй авылындагы юлларны кардан чистарту);

2) су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (Песәй авылында скважиналар өчен 2 (ике) данә тирәнлек насослары сатып алу);

3) янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (Песәй авылының Яшьләр урамында, Тукай урамында янгыннарны күзәтү өчен видеокүзәтү камералары урнаштыру)»?

«РИЗА» «КАРШЫ»

5. Әлеге карарны Песәй авылында махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларына, шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталына http://pravo.tatarstan.ru урнаштырып халыкка җиткерергә һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында www.mendeleevsk.tatar.ru "Песәй авыл җирлеге" бүлегендә урнаштырырга

6. Әлеге карар халыкка игълан ителгән көненнән үз көченә керә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Менделеевск муниципаль районы
Песәй авыл җирлеге башлыгы _____________ В.И.Мөхәммәтгалеев
(имза) (имзаның аңлатмасы)